РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**28 февраль 2019 ел.** **Чистай шәһәре** **№32/1**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре”муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары Кагыйдәсенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары Кагыйдәсенә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны тыңлап һәм тикшереп, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре буенча комиссия нәтиҗәсен һәм 26.12.2018 елда, 10.01.2019елда һәм 28.01.2019 елда үткәрелгән ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары Кагыйдәсенең 1нче өлешенә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының 19.12. 2012 елгы (Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының 29.08. 2018 елгы 27/1 нче карары редакциясендә) 18/7нче карары белән расланган үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1нче маддәнең 10нчы абзацын “капиталь ремонт” сүзләреннән соң “,сүтү” сүзе белән тулыландырырга;

1.2 14 нче маддәне түбәндәге эчтәлектәге 11нче пункт белән тулыландырырга:

“ Җирле үзидарә органына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32нче маддәсенең 2 нче өлешендә күрсәтелгән дәүләт властеның башкарма органыннан, вазифаи заттан, дәүләт учреждениесеннән яки җирле үзидарә

органыннан рөхсәтсез төзелгән корылманы ачыклау турында белдерү кергән көннән шундый корылма урнашкан яки шундый корылманы сүткәнчегә кадәр яки аны билгеләнгән таләпләр нигезендә тәртипкә китергәнче әлеге җир участогына карата файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мөмкин түгел, җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге белдерү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32нче маддәсенең 2 нче өлешендә күрсәтелгән дәүләт властеның башкарма органында, вазифаи затта, дәүләт учреждениесендә яки җирле үзидарә органында каралган һәм әлеге белдерү алардан кергән очраклардан кала, рөхсәтсез төзелгән корылма билгеләре булу каралмавы яисә рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү турындагы иск таләпләрен канәгатьләндерүдән яки аны билгеләнгән таләпләр нигезендә тәртипкә китерүдән баш тарту турында суд карары законлы көченә керү турында белдерү җибәрелгән.»;

1.3. 15 нче маддәне түбәндәге эчтәлектәге 4нче пункт белән тулыландырырга:

“4. Җирле үзидарә органына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32нче маддәсенең 2 нче өлешендә күрсәтелгән дәүләт властеның башкарма органыннан, вазифаи заттан, дәүләт учреждениесеннән яки җирле үзидарә органыннан рөхсәтсез төзелгән корылманы ачыклау турында белдерү кергән көннән әлеге җир участогына карата рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә чыгуга рөхсәт бирү мөмкин түгел, җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге белдерү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32нче маддәсенең 2 нче өлешендә күрсәтелгән дәүләт властеның башкарма органында, вазифаи затта, дәүләт учреждениесендә яки җирле үзидарә органында каралган һәм әлеге белдерү алардан кергән очраклардан кала, рөхсәтсез төзелгән корылма билгеләре булу каралмавы яисә рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү турындагы иск таләпләрен канәгатьләндерүдән яки аны билгеләнгән таләпләр нигезендә тәртипкә китерүдән баш тарту турында суд карары законлы көченә керү турында белдерү җибәрелгән.»;

1.4. түбәндәге эчтәлектәге 20.1 маддә белән тулыландырырга:

“ 20.1нче маддә. Территорияне планлаштыру турында гомуми нигезләмәләр

1. Территорияне планлаштыру буенча гамәлләрнең эчтәлеге һәм тәртибе Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы,Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон, муниципаль хокукый актлар, әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнә.

2. Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, шул исәптән планировка структурасы элементларын бүлү, җир участокларының чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын урнаштыруны планлаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатында әзерләнә.

Капиталь төзелеш объектларын территориягә (аның чикләрендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру

каралмаган) кулланып урнаштыру максатында территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү таләп ителми, әлеге маддәнең 3нче пунктында күрсәтелгән очраклардан кала.

3. Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру максатында территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү түбәндәге очракларда мәҗбүри булып тора:

1) федераль, төбәк яки җирле билгеләнештәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру уңаеннан дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җир участокларын тартып алу зарури;

2) кызыл линияләрне билгеләргә, үзгәртергә яки кире кагарга кирәк;

3) җир законы нигезендә җир участокларын оештыру бары тик территорияне межалау проекты нигезендә генә гамәлгә ашырылган очракта җир участокларын оештыру зарур;

4) капиталь төзелеш объектларын уртак чикләре булган ике яки берничә муниципаль берәмлекләр территориясендә урнаштыру планлаштырыла (шундый капиталь төзелеш объектларын урнаштыру дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир участокларында тормышка ашыру планлаштырылган очрактан кала, һәм шундый капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен дәүләт яки муниципаль милектә булган җир участокларын бирү һәм сервитутлар урнаштыру таләп ителми);

5) төзелеш, линия объектын реконструкцияләү планлаштырыла (линия объектын урнаштыру дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир участокларында тормышка ашыру планлаштырылган очрактан кала, һәм шундый линия объектын урнаштыру өчен дәүләт яки муниципаль милектә булган җир участокларын бирү һәм сервитутлар урнаштыру таләп ителми). Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башка очраклар да билгеләнергә мөмкин, бу вакытта төзелеш, линия объектын реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми.

4. Территорияне планлаштыру буенча документ төрләре булып торалар:

1) территорияне планлаштыру проекты;

2) территорияне межалау проекты.

5. Чикләрендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлекне тормышка ашыру каралмаган, шулай ук линия объектларын урнаштыру планлаштырылмаучы территориягә карата түбәндәге максатларда территорияне планлаштыру проектын әзерләмичә генә территорияне межалау проектын әзерләү рөхсәт ителә:

1) оештырыла һәм үзгәртелә торган җир участоклары чикләренең урнашу урынын билгеләү;

2) төзелгән территорияләр өчен кызыл линияләрне урнаштыру, үзгәртү, кире кагу, аларның чигендә яңа капиталь төзелеш объектларын урнаштыру планлаштырылмый, шулай ук территориягә карата аның чикләрендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру каралмаучы территория чикләрендә урнашкан җир участогын оештыру һәм (яки) үзгәртү сәбәпле, кызыл линияләрне урнаштыру, үзгәртү, кире кагу

өчен, әгәр шундый урнаштыру, үзгәртү, кире кагу гомуми кулланылыштагы территория чикләрен үзгәртүгә китерсә.

6. Территорияне планлаштыру проекты территорияне межалау проекты әзерләү өчен нигез булып тора, әлеге маддәнең 5нче пунктында каралган очраклардан кала. Территорияне межалау проектын әзерләү территорияне планлаштыру проекты составында яки аерым документ төрендә тормышка ашырыла.

7. Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү турындагы карарны Башкарма комитет кабул итә, әлеге маддәнең 8нче пунктында күрсәтелгән очраклардан кала.

8. Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү турындагы карар мөстәкыйль рәвештә кабул ителә:

1) төзелгән территорияне үстерү турында килешүләр төзелгән, территорияне комплекслы үзләштерү турында килешүләр, шул исәптән икътисадый сыйныф тораклары төзү максатында, җирле үзидарә органнары инициативасы буенча территорияне комплекслы үстерү килешүләре төзелгән затлар тарафыннан;

2) территорияне комплекслы үстерү чикләрендә урнашкан җир участокларының һәм (яки) күчемсез милек объектларының бер яки берничә хуҗасы белән, шул исәптән дәүләт яки муниципаль милектә булган җир участоклары аларга арендага, бушлай файдалануга бирелгән затлар тарафыннан;

3) реконструкцияләнергә тиешле гамәлдәге линия объектлары ияләре тарафыннан, әгәр территорияне планлаштыру буенча документлар аларны реконструкцияләү максатында әзерләнгән булса;

4) табигый монополия субъектлары, коммуналь комплекслар оешмалары тарафыннан, әгәр территорияне планлаштыру буенча документлар федераль билгеләнештәге объектлар, төбәк билгеләнешендәге объектлар, җирле билгеләнештәге объектлар урнаштыру өчен әзерләнгән булса;

9. Әлеге маддәнең 8нче пунктында каралган очракларда, территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү күрсәтелгән затлар тарафыннан алар акчасы хисабына мөстәкыйль рәвештә яки Россия Федерациясе законнары нигезендә җәлеп ителүче оешмалар тарафыннан тормышка ашырыла. Күрсәтелгән затларның территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләүгә чыгымнары Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетлары акчасы хисабына капланмый.

10. Территорияне планлаштыру буенча документларның состав, әзерләү тәртибе, килештерү, тикшерү һәм раслау шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон нигезендә һәм әлеге Кагыйдәләрне исәпкә алып билгеләнә.”;

1.5. 25 нче маддәнең 2нче пунктында:

1.5.1. 1нче пунктчада “гараж төзү” сүзен “гараж төзү, реконструкцияләү” сүзләре белән алмаштырырга;

1.5.2. 2нче пунктчада “бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару өчен бирелгән җир участогында төзү” сүзләрен “ бакча җир участогында торак йорт, бакча өе, хуҗалык корылмалары төзү, реконструкцияләү” дигән сүзләргә алмаштырырга;

1.5.3. түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пункт белән тулыландырырга:
“2.1) шәхси торак төзелеше объектларын төзү, реконструкцияләү;”;
1.6. 26нчы маддәдә:
1нче пунктның 2нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
1.6.1. “шәхси торак төзелеше, бакча өе объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә проект документациясен әзерләүне гамәлгә ашыру таләп ителми. Төзүче үз инициативасы белән шәхси торак төзелеше, бакча өе объектына карата проект документациясе әзерләүне тәэмин итәргә хокуклы.”;
1.6.2. 8нче пунктның 7нче пунктчасында “яки сүтү” сүзен һәм “яки сүтәргә” сүзен алып ташларга;
1.6.3.8нче пунктның 10нчы пунктчасында “капиталь ремонт” сүзен “,сүтү” сүзе белән тулыландырырга;
1.6.4. 8нче пунктның 2нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48нче маддәсенең 13 нче өлеше белән каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып капиталь төзелеш объектларының проект документациясе составына түбәндәге бүлекләр кертелә:
1) капиталь төзелеш объектларын архитектур-төзелеш проектлавы, төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, шул исәптән инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру өчен (технологик кушу) булган мәгълүматлар белән аңлатмалы язу, инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза үткәргән очракта проект документациясенә экспертиза үткәргәнгә кадәр реквизитлар белән инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертизаның уңай нәтиҗәсе;
2) җир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә үтәлгән җир участогын планлы оештыру схемасы, линия объектларына карата проект документациясен әзерләгән очракта территорияне планлаштыру проекты нигезендә эшләнгән читкә чыгару полосасы проекты
(линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителмәгән очрактан кала);
3) үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән архитектур, функциональ-технологик, конструктив, инженер-техник карарлар һәм (яки) чаралар булган бүлекләр:
а) техник регламентлар таләпләре, шул исәптән механик, янгын һәм башка куркынычсызлык таләпләре, энергетик нәтиҗәлелек таләпләре биналарга һәм корылмаларга карата энергетик ресурслардан файдаланучы исәпкә алу приборлары булган , бинаны, төзелеш корылмаларын җиһазландыру таләпләре ( шул исәптән алар составына керүче инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә һәм системаларына), инвалидларның капиталь төзелеш объектларына керүен-чыгуын тәэмин итүгә таләпләр (әгәр проект документациясе сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм башка социаль-мәдәни һәм коммуналь көнкүреш билгеләнешендәге объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына,эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонд объектларына карата проект документациясе әзерләнсә);

б) санитар-эпидемиологик таләпләр, әйләнә-тирә мохитны саклау өлкәсендәге таләпләр, атом энергиясен имин файдалануга таләпләр, сәнәгать иминлеге таләпләре, электроэнергетик системалар һәм электроэнергетика объектларының ышанычлылыгын һәм иминлеген тәэмин итүгә таләпләр һәм объектларның террорга каршы сакланышына таләпләр;

в) проектлау, төзү, монтажлау, көйләү, биналарны һәм корылмаларны файдалану процессларына таләпләр;

г) капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның (технологик кушуның) техник шартларына таләпләр;

4) капиталь төзелеш объектларын төзүне оештыру проекты;

5) капиталь төзелеш объектларыннан имин файдалануны тәэмин итүгә таләпләр;

6) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкаруның норматив дәвамлылыгы турында белешмә, алар шундый объектны имин файдалануны тәэмин итү өчен кирәк, шулай ук күп фатирлы йортны төзү, реконструкцияләү өчен проект документациясе әзерләгән очракта күрсәтелгән эшләрнең күләме һәм составы турындагы белешмә.”;

1.6.5. 8нче пунктның 15нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Экспертизага һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеге органына тәкъдим ителүче проект документациясе бүлекләре составына һәм эчтәлегенә таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә һәм капиталь төзелеш объектларының төрле төрләренә карата (шул исәптән линия объектларына) бүленә, шулай ук капиталь төзелеш объектларының билгеләнешенә, эшләр төренә (капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау), аларны карап тотуга, эшләрне финанслау чыганакларына һәм төзүнең, реконструкцияләүнең аерым этапларын күрсәтүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 нче маддәсе таләпләре нигезендә, түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алып:

1) проект документациясен әзерләү капиталь төзелеш объектларының төрле төрләренә (шул исәптән линия объектларына) карата аерым бүлекләр күләмендә, шулай ук проектлауга төзүче яки техник заказ бирүче биремнәре нигезендә капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләгәндә (капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү эшләрен башкарганда) эшләрнең күләменә бәйле рәвештә тормышка ашырыла;

2) капиталь төзелеш объектларын төзүне башкару проекты капиталь төзелеш объектларын, аларның аерым өлешләрен сүтү буенча эшләр проектыннан торырга тиеш, ( әгәр капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү өчен капиталь төзелеш объектларын, аларның аерым өлешләрен сүтү зарури булса);

3) проект документациясендә булган карарлар һәм чаралар Россия Федерациясенең мәдәни мирас объектларын саклау турындагы законы таләпләренә туры килергә тиеш (әгәр проект документациясе мирас объектларын саклау буенча эшләр үткәрү өчен әзерләнсә, бу вакытта шундый объектларның ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары әләгә);

4) проект документациясе ”Капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга, сүтүгә смета” ( әгәр төзү, реконструкцияләү, сүтү Россия Федерациясе бюджет системасының бюджет акчасын, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8.3 нче маддәсенең 2нче өлешендә күрсәтелгән юридик затлар акчасын җәлеп итеп финансланса, капиталь ремонт Россия Федерациясе бюджет системасының бюджет акчасын, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8.3 нче маддәсенең 1нче өлешендә күрсәтелгән затлар акчасын җәлеп итеп финансланса);

5) 1997 елның 21 июлендә кабул ителгән “ Куркыныч производство объектларының сәнәгать иминлеге турында”гы 116 нчы Федераль законның 14 нче маддәсенең 3 нче пункты,1997 елның 21 июлендә кабул ителгән “ Гидротехник корылмаларның иминлеге турында”гы 117 нче Федераль законның 10 нчы маддәсе, 1995 елның 21 ноябрендә кабул ителгән “ Атом энергиясеннән файдалану турында”гы 170 нче Федераль законның 30 нчы маддәсе, 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында”гы 73 нче Федераль законның 36 нчы маддәсенең 2 һәм 3 нче пунктлары белән каралган очракларда проект документациясе составына мәҗбүри рәвештә федераль законнар белән күрсәтелгән документлар, проект документациясе бүлекләре кертелә.”;

1.7 27нче маддәдә:

1.7.1 4нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре экспертизасы нәтиҗәсе булып инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең техник регламентларга тәңгәл килүе (уңай нәтиҗә) яки тәңгәл килмәве (тискәре нәтиҗә) тора. Проект документациясе экспертизасы нәтиҗәсе булып нәтиҗә тора:

1) проект документациясенең инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең, проектлау биремнәренең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 нче маддәсенең 5нче өлешенең 1 нче пункты белән каралган таләпләргә тәңгәл килүе (уңай нәтиҗә) яки тәңгәл килмәве (тискәре нәтиҗә) турында (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49нчы маддәсенең 3.3 нче өлешенең 1нче пункты нигезендә проект документациясенә экспертиза үткәрү очракларыннан кала);

2) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8.3 нче маддәсенең 2нче өлеше белән билгеләнгән очракларда капиталь төзелеш объектларын төзүнең смета бәясен билгеләүнең дөреслеге (уңай нәтиҗә) яки дөрес булмавы (тискәре нәтиҗә) турында.”;

5нче пунктның 3нче пунктчасындагы 8нче абзацындагы “яки сүтәргә” сүзен алып ташларга

1.7.2 6нчы пункт үз көчен югалткан дип танырга;

1.7.3 8нче пунктның өченче абзацында “ яки шәхси торак төзелеше объектын урнаштыру урынын билгеләп җир участогын төзүнең планлаштырылган схемасы” һәм “яки җир участогын төзүне планлаштыруның күрсәтелгән схемасы” дигән сүзләрне алып ташларга;

1.8 түбәндәге эчтәлектәге 27.1нче маддә белән тулыландырырга:

“ 27.1нче маддә. Шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзүне яки реконструкцияләүне планлаштыру турында белдерү

1. Шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзү яки реконструкцияләү максатында төзүче Башкарма комитетка шәхси мөрәҗәгать итү чарасы белән кәгазьдә, шул исәптән күпфункцияле үзәк аша яисә күрсәтелгән органнарга тапшыру турындагы белдерү белән почта яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзүне яки реконструкцияләүне планлаштыру турындагы белдерүне җибәрә (алга таба – планлаштырылган төзелеш турында белдерү), ул түбәндәге хәбәрләрдән тора:

1) төзүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (әгәр ул булса), яшәү урыны, шәхесен раслаучы документ ( физик зат өчен) реквизитлары;

2) төзүченең ( юридик зат өчен) исеме һәм урнашу урыны, шулай ук юридик затның бердәм дәүләт реестрында юридик затны дәүләт теркәве турындагы язуның дәүләт теркәве номеры һәм салым түләүченең идентификацион номеры, әгәр гариза бирүче чит ил юридик заты булмаса;

3) җир участогының кадастр номеры (әгәр ул булса), адресы яки җир участогының урнашу урынын тасвирлау;

4) төзүченең җир участогына хокукы турында белешмә, шулай ук җир участогына башка затларның (шундый затлар булганда) хокукы булу-булмау турындагы белешмә;

5) җир участогыннан һәм капиталь төзелеш объектын (шәхси торак төзелеше яки бакча өе объекты) файдалануның рөхсәт ителгән төре турында белешмә;

6) шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының планлаштырылган параметрлары турында белешмә, аларны төзү һәм реконструкцияләү максатында планлаштырылган төзелеш, шул исәптән җир участогы чикләреннән читкә чыгу турында белдерү бирелгән;

7) шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының күчемсез милекнең мөстәкыйль объектларына бүлү өчен билгеләнмәве турындагы белешмә;

8) төзүче белән элемтәгә керү өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы;

9) төзүчегә әлеге маддәнең 7нче пунктының 2нче пунктчасы һәм 8нче пунктының 3нче пунктчасы белән каралган белдерүне җибәрү ысулы.

2.Планлаштырыла торган төзелеш турындагы белдерү формасы төзелеш, архитектура, шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт сәясәтен һәм норматив-хокукый көйләүне эшләү һәм тормышка ашыру буенча функцияләр үтәүче башкарма властьның федераль органы тарафыннан раслана. 3.Планлаштырылган төзелеш белдерүенә беркетелә:

1) җир участогына хокукны раслаучы документлар, әгәр аңа хокук күчемсез милекнең бердәм дәүләт ресстрында теркәлмәгән булса;

2) төзүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ, әгәр планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүе төзүче вәкиле тарафыннан җибәрелгән булса;

3) чит дәүләт законы нигезендә юридик затны дәүләт теркәве турындагы документларның рус теленә раслатылган тәрҗемәсе, әгәр төзүче булып чит илнең юридик заты торса;

4) шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының тышкы күренешен тасвирлау, әгәр шәхси торак яки бакча өе төзелеше объектын төзү яки реконструкцияләү федераль яки төбәк билгеләнешендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылса, әлеге маддәнең 5нче өлеше белән каралган очрактан кала. Шәхси торак яки бакча өе төзелеше объектының тышкы күренешен тасвирлау үз эченә текст формасында тасвирлауны һәм график тасвирлауны ала. Шәхси торак яки бакча өе төзелеше объектының тышкы күренешен текст формасында тасвирлау үз эченә түбәндәгеләрне күрсәтүне ала: шәхси торак яки бакча өе төзелеше объекты параметрлары, аларның тышкы күренешенең төсләр чишелеше, файдалану өчен планлаштырылучы төзелеш материаллары, алар шәхси торак яки бакча өе төзелеше объектының тышкы күренешен билгели, шулай ук шәхси торак яки бакча өе төзелеше объектының башка характеристикаларын тасвирлау, аларга таләпләр шәһәр төзелеше регламенты белән капиталь төзелеш объектының архитектур карарларына таләпләр сыйфатында билгеләнгән. График тасвирлау шәхси торак яки бакча өе төзелеше объектының тышкы күренеше сурәтендә, үз эченә шәхси торак яки бакча өе төзелеше объекты фасадын һәм конфигурациясен ала.

4. Әлеге маддәнең 3нче пунктының 1 нче пунктчасында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки алардагы белешмәләр) әлеге маддәнең 1нче пунктының беренче абзацында күрсәтелгән әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары ведомствосындагы органнар тарафыннан планлаштырылган төзелеш турында белдерү алган көннән өч эш көненнән дә соңга калмаган срокта соратыла, әгәр төзүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль рәвештә тәкъдим итмәгән булса. Әлеге маддәнең 1нче пунктының беренче абзацында күрсәтелгән органнарның ведомствоара сораулары буенча әлеге маддәнең 3нче пунктының 1 нче пунктчасында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки алардагы белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары ведомствосындагы оешмалар тарафыннан тиешле ведомствоара сорауны алганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмаган срокта бирелә.

5. Төзүче шәхси торак яки бакча өе төзелеше объектын төзүне яки реконструкцияләүне федераль яки төбәк билгеләнешендәге тарихи җирлек чикләрендә 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында”гы 73 нче Федераль закон нигезендә расланган капиталь төзелеш объектының типовой архитектур карары нигезендә тормышка ашырырга хаклы. Бу очракта планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүгә шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының тышкы күренешен тасвирлау кушымтасы таләп ителми.

6. Планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүдә әлеге маддәнең 1нче пункты белән каралган хәбәрләр яки әлеге маддәнең 3нче пунктының 2-4 нче пунктчалары белән каралган документлар булмаган очракта, төзелешкә рөхсәт бирү вәкаләте булган җирле үзидарә органы планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүне алган көннән соң өч эш көне дәвамында төзүчегә әлеге белдерүне һәм аңа беркетелгән документларны карармыйча кире кайтару сәбәбен күрсәтеп кире кайтара. Бу очракта планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү җибәрелмәгән дип санала.

7. Төзелешкә рөхсәт бирү вәкаләте булган җирле үзидарә органы планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү кергән көннән соң җиде эш көне дәвамында, әлеге маддәнең 8 нче пункты белән каралган очраклардан кала, түбәндәгеләрне эшли:

1) планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объекты параметрларының билгеләнгән җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре тарафыннан, территорияләрне планлаштыру буенча документацияләр белән, Шәһәр төзелеше кодексы, башка федераль законнар һәм планлаштырылган төзелеш турында белдерү керү көненә гамәлдә булган, шулай ук Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән җир участогыннан файдалануга рөхсәт һәм чикләүләр нигезендә шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын урнаштыру мөмкинлеге белән рөхсәт ителгән капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларына туры килүен тикшерү үткәрә;

2) төзүчегә планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүдә аның тарафыннан билгеләнгән ысул белән планлаштырылган шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзү параметрларының белдерүдә күрсәтелгән параметрларга тәңгәл килүе һәм җир участогында шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын урнаштыру мөмкинлеге турында яисә планлаштырылган шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзү параметрларының белдерүдә күрсәтелгән параметрларга тәңгәл килмәве һәм (яки) җир участогында шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын урнаштыру мөмкин булмавы турында белдерү җибәрә. Планлаштырылган шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзү параметрларының белдерүдә күрсәтелгән параметрларга тәңгәл килүе һәм җир участогында шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын урнаштыру мөмкинлеге турында яисә планлаштырылган шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзү параметрларының белдерүдә күрсәтелгән параметрларга тәңгәл килмәве һәм (яки) җир участогында шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын урнаштыру мөмкин булмавы турындагы белдерү формалары төзелеш, архитектура, шәһәр төзелеше өлкәсендә норматив-хокукый көйләү һәм дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма властьнең федераль органы тарафыннан раслана.

8. Әгәр шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзү яки реконструкцияләү федераль яки төбәк билгеләнешендәге тарихи җирлек чикләрендә планлаштырылса, планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүдә шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзү яки

реконструкцияләү планлаштырылган типовой архитектур карарга күрсәтү булмый, төзелешкә рөхсәт бирү вәкаләте булган җирле үзидарә органы түбәндәгеләрне эшли:

1) әлеге белдерү кергән көннән соң аны кире кайтару өчен әлеге маддәнең 6нчы пункты белән каралган сәбәпләр булмаганда, белдерүне өч эш көне эчендә җибәрә, шул исәптән бердәм ведомствоара электрон үзараэлемтә системасыннан һәм аңа тоташтырылган бердәм ведомствоара электрон үзараэлемтәнең төбәк системасыннан файдаланып, Россия Федерациясе субъектының мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләте булган башкарма власть органына күрсәтелгән белдерүне һәм аңа кушымта итеп шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының тышкы күренешен тасвирлауны җибәрә;

2) әлеге белдерүдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объекты параметрларының билгеләнгән җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре тарафыннан, территорияләрне планлаштыру буенча документацияләр белән, Шәһәр төзелеше кодексы, башка федераль законнар һәм планлаштырылган төзелеш турында белдерү керү көненә гамәлдә булган, шулай ук Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән җир участогыннан файдалануга рөхсәт һәм чикләүләр нигезендә шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын урнаштыру мөмкинлеге белән рөхсәт ителгән капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларына туры килүенә тикшерү үткәрә;

3) төзүчегә әлеге белдерү кергәннән көннән егерме эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге белдерүдә аның тарафыннан билгеләнгән ысул белән әлеге маддәнең 7нче пунктының 2нче пунктчасы белән каралган планлаштырылган шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзү параметрларының белдерүдә күрсәтелгән параметрларга тәңгәл килүе һәм җир участогында шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын урнаштыру мөмкинлеге турында яисә планлаштырылган шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзү параметрларының белдерүдә күрсәтелгән параметрларга тәңгәл килмәве һәм (яки) җир участогында шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын урнаштыру мөмкин булмавы турында белдерү җибәрә.”;

1.9. 28 нче маддәнең 10нчы пунктында “күзәтү” сүзеннән соң “капиталь төзелеш объектларына карата” сүзләрен өстәргә, “техник регламентлар” сүзен алып ташларга, “энергетик нәтиҗәлелек” сүзләреннән соң “(энергетик нәтиҗәлелек таләпләре таралмый торган капиталь төзелеш объектларыннан кала” дигән сүзләрне өстәргә”;,

1.10. 29нчы маддәдә:

1.10.1. 3нче пунктның 5нче пунктчасын көчен югалткан дип танырга;

1.10.2. 3нче пунктның 6нчы пунктчасында “документ” сүзен “акт” сүзе белән алыштырырга, “,шәхси торак төзелеше объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашыру очракларыннан кала” дигән сүзләрне алып ташларга.

1.10.3. 3нче пунктның 9нчы пунктчасында “(дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру каралган очракта)” дигән сүзләрне “(дәүләт төзелеш

күзәтчелеген гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 нче маддәсенең 1нче өлеше белән каралган очракта)" дигән сүзләр белән алыштырырга, "техник регламентлар һәм" дигән сүзләрне алып ташларга;
1.10.4. 5нче пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
" – төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының параметлары проект документациясенә тәңгәл килми.";
1.10.5. 5нче пунктның 6 һәм 7нче абзацларын көчен югалткан дип танырга;
1.11. 30нчы маддәнең 8нче пунктын "техник регламентлар" сүзләреннән соң "Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт рессстры белешмәләре, шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүче дәүләт мәгълүмат системаларында булган белешмәләр, документлар, материаллар" дигән сүзләр белән тулыландырырга.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары Кагыйдәсенең III өлешенең 11нче бүлегенең 36нчы маддәсенә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының 19.12. 2012 елгы 18/7нче карары (Чистай шәһәре Советының 30.06.2016елгы №7/1нче, 25.08.2016 елгы №8/4нче, 28.09.2017елгы №18/4нче карарлары редакциясендә) белән расланган түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
2.1. Ж-1""Шәхси торак йортлар төзелгән зона" бүлегенең соңгы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

" Җир участокларының чик күләмнәре аста китерелгән таблица күрсәткечләренә тәңгәл килергә тиеш.

| Параметрлар төре һәм үлчәү берәмлекләре | | Күчемсез милектән файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрлар күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|
| | | Шәхси торак төзелеше өчен | Блокировкаланган торак корылма |
| Җир участокларының чик параметрлары | | | |
| Минималь мәйдан | кв.м | 400 | 400 |
| Максималь мәйдан | кв.м | 1500 | 1500 |
| Участок чикләрендә рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрлары | | | |
| Участок төзелешенең максималь проценты | % | 40,5 | 55 |
| Участокның алгы чиgennән корылманың минималь чыгып торуы (әгәр корылманы | м | 3 | 3 |

| | | Күчемсез милектән файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрлар күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|
| көйләү линиясенең башка күрсәткече билгеләнмәгән булса) Параметрлар төре һәм үлчәү берәмлекләре | | | |
| Участокның ян-як чигеннән корылманың минималь чыгып торуы | м | а) 1-брандмауэр дивары булганда мәҗбүри;<br>б) 3 – башка очракларда | а) 0 –янәшәдәге блокларга терәлеп торганда;<br>б) 3 - башка очракларда |
| Участокның арткы чигеннән корылманың минималь чыгып торуы | м | 3 | 3<br>(әгәр корылманы көйләү линиясе белән башкасы билгеләнмәгән булса) |
| Корылманың максималь биеклеге | м | 12 | 12 |
| Җир участогы коймасының максималь биеклеге | м | 2,0* | 1,2* |

* Чиктәш участоклар арасындагы бакчалар алып торган өлешендәге коймалар материалы һәм төре табигый яктылыкны чикләмәүче материаллардан кабул ителә.

Таблицага искәрмә

1нче искәрмә. Җир участогының чик параметрлары күрсәткечләре таблицасында күрсәтелгән читкә чыгу рөхсәт ителә, әлеге Кагыйдәләрне кабул итүгә кадәр файдаланылган фактта һәм җир участогы мәйданын нормативка кадәр арттыру мөмкинлеге юк, әгәр шундый участокта урнашкан капиталь төзелеш объекты төзелеше төгәлләү елы әлеге Кагыйдәләрне кабул итү датасына кадәр булса.

2нче искәрмә. Даими рәвештә Чистай муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарга бирелә торган, Чистай шәһәре чикләрендә урнашкан җир участокларының чик күләме, гражданнарның җир участогын милеккә бирү (тапшыру) турындагы гариза бирү көненә унсигез яше тулмаган өч һәм аннан артыграк балалары, шул исәптән үги уллары, кызлары, шулай ук уллыкка (кызлыкка) һәм опекага (аларга карата опека сроксыз гамәлгә ашырыла, яисә алар балигъ булганчыга кадәр) алган балалары булса:

- шәхси торак төзүне, дача төзүне, бакчачылык яки яшелчәчелекне гамәлгә ашыру өчен - 700 кв.м.дан 900 кв.м.га кадәр.

Гаражлар төзү һәм урнаштыру, хуҗалык корылмалары төзү өчен бирелә торган җир участокларының чик күләмнәре планлаштыруның эшләнгән һәм

расланган проектын һәм аста китерелгән таблица күрсәткечләрен исәпкә алып СНиП нормаларына туры килергә тиеш

| Параметрлар төре һәм үлчәү берәмлекләре | | Күчемсез милектән файдалануның ярдәмче һәм шартлы рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрлар күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | бакчалар, (дачалар) | яшелчә челек | Шәхси гаражлар | Хуҗалык корылмалары |
| Җир участогының чик параметрлары | | | | | |
| Минималь мәйдан | кв.м | 400 | 400 | 20 | 10 |
| Максималь мәйдан | кв.м | 600 | 600 | 35 | 20 |

* Чиктәш участоклар арасындагы бакчалар алып торган өлешендәге коймалар материалы һәм төре табигый яктылыкны чикләмәүче материаллардан кабул ителә.

Таблицага искәрмә

1нче искәрмә. Җир участогының чик параметрлары күрсәткечләре таблицасында күрсәтелгән читкә чыгу рөхсәт ителә, әлеге Кагыйдәләрне кабул итүгә кадәр файдаланылган фактта һәм җир участогы мәйданын нормативка кадәр арттыру мөмкинлеге юк, әгәр шундый участокта урнашкан капиталь төзелеш объекты төзелеше төгәлләү елы әлеге Кагыйдәләрне кабул итү датасына кадәр булса. ";

2.2. "Ж-2. Урта катлы торак йортлар корылмалары зонасы" бүлегенең соңгы абзацын бәян итеп:

" Җир участокларының чик күләмнәре аста китерелгән таблица күрсәткечләренә тәңгәл килергә тиеш.

| Параметрлар төре һәм үлчәү берәмлекләре | | Күчемсез милектән файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрлар күрсәткечләре | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 3 каттан биек булмаган күп фатирлы йортлар | Блокировкалан ган торак корылма | 4 -5 катлы күп фатирлы йортлар |
| Җир участокларының чик параметрлары | | | | |
| Минималь мәйдан | кв.м | 600 | 400 | 1200 |
| Максималь мәйдан | кв.м | - | 1500 | - |
| Участок | | | | |

| | | Күчемсез милектән файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрлар күрсәткечләре | | |
|---|---|---|---|---|
| чикләрендә рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрлары Параметрлар төре һәм үлчәү берәмлекләре | | | | |
| Участок төзелешенең максималь проценты | % | 50 | 55 | 50 |
| Участокның алгы чигеннән корылманың минималь чыгып торуы (әгәр корылманы көйләү линиясенең башка күрсәткече билгеләнмәгән булса) | м | 3 | 5 | 3 |
| Участокның ян-як чигеннән корылманың минималь чыгып торуы | м | 6 | а) 0 – янәшәдәге блокларга терәлеп торганда; б) 3 - башка очракларда | 8 |
| Участокның арткы чигеннән корылманың минималь чыгып торуы | м | 6 | 3 (әгәр корылманы көйләү линиясе белән башкасы билгеләнмәгән булса) | 10 |
| Корылманың максималь биеклеге | м | 13 | 12 | 21 |

Гаражлар төзү һәм урнаштыру, хуҗалык корылмалары төзү өчен бирелә торган җир участокларының чик күләмнәре планлаштыруның эшләнгән һәм расланган проектын һәм аста китерелгән таблица күрсәткечләрен исәпкә алып СНиП нормаларына туры килергә тиеш

| Параметрлар төре һәм үлчәү берәмлекләре | | Күчемсез милектән файдаланунын ярдәмче һәм шартлы рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрлар күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | бакчалар, (дачалар) | яшелчәле кләр | Шәхси гаражлар | Хуҗалык корылмалары |
| Җир участогының чик параметрлары | | | | | |
| Минималь мәйдан | кв.м | 400 | 400 | 20 | 10 |
| Максималь мәйдан | кв.м | 600 | 600 | 35 | 20 |

* Чиктәш участоклар арасындагы бакчалар алып торган өлешендәге коймалар материалы һәм төре табигый яктылыкны чикләмәүче материаллардан кабул ителә.

Таблицага искәрмә

1нче искәрмә. Җир участогының чик параметрлары күрсәткечләре таблицасында күрсәтелгән читкә чыгу рөхсәт ителә, әлеге Кагыйдәләрне кабул итүгә кадәр файдаланылган фактта һәм җир участогы мәйданын нормативка кадәр арттыру мөмкинлеге юк, әгәр шундый участокта урнашкан капиталь төзелеш объекты төзелеше төгәлләү елы әлеге Кагыйдәләрне кабул итү датасына кадәр булса.”.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары Кагыйдәсенең Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре территориясен шәһәр төзелеше зоналарына бүлү картасының 1нче кушымтасына Чистай шәһәре Советының 19.12.2012елгы 18/7 нче карары (Чистай шәһәре Советының 30.06.2016 елгы 7/1нче, 25.08.2016 елгы 8/4 нче, 27.04.2017 елгы 14/5нче, 28.09.2017 елгы 18/4нче , 2.11.2017 елгы 19/2 нче, 14.12.2017 елгы 20/13нче, 21.03.2018 елгы 23/5 нче, 29.08.2018 елгы 27/1 нче, 24.10.2018елгы 28/5нче, 25.12. 2018 елгы 30/12нче карарлары редакциясендә) белән расланган үзгәрешләрне кертергә:

- Ж-4 “Бакчачылык һәм дача участоклары” төзелеш корылмалары территориаль зонасы чикләрен үзгәртү өлешендә һәм «Пищевик» ДС һәм ОНТ, Татарстан Республикасы,Чистай шәһәре, 263нче участок чикләрендәге территорияне, шул исәптән кадастр номеры 16:54:120401:420, мәйданы 400 кв.м. булган җир участогын Ж-1 “Шәхси торак йортлар төзелгән зона” төзелеш корылмалары зонасына кертергә (1нче кушымта);

- ПК-2 “III класслы куркынычлылыклы производство-коммуналь объектлар зонасы” төзелеш корылмалары территориаль зонасы чикләрен үзгәртү өлешендә һәм Татарстан Республикасы,Чистай шәһәре, Энгельс урамы, 140Б чикләрендәге территорияне, шул исәптән кадастр номеры16:54:020103:480, мәйданы 4448 кв.м. булган җир участогын Д-4 “Спорт һәм спорт-тамаша билгеләнешендәге объектларны урнаштыру зонасы” төзелеш корылмалары

зонасына  кертергә (2нче кушымта);
- Ж-1"“Шәхси торак йортлар төзелгән зона” төзелеш корылмалары территориаль зонасы  чикләрен үзгәртү өлешендә  һәм Чистай шәһәре, Энгельс урамы, 45 нче йорт чикләрендәге территорияне, шул исәптән кадастр номеры16:54:080502:1, мәйданы  629  кв.м. булган  җир участогын Д-1 “Эшлекле, җәмәгать һәм коммерцияви билгеләнештәге  зона” төзелеш корылмалары зонасына  кертергә (3нче кушымта );

- Д-3 “Мәгариф һәм фәнни комплексларын объектларын урнаштуры зонасы”, СН-4 “ Махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасы”, Р-1”Рекреацион-ландшафтлы территорияләр зонасы” төзелеш корылмалары территориаль зонасы  чикләрен үзгәртү өлешендә  һәм Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре М.Поликарпова урамы, 2В чикләрендәге территорияне, шул исәптән кадастр номеры 16:54:000000:869, мәйданы  26458,0  кв.м. булган  җир участогын ПК-3 “IV-V класслы куркынычлылыктагы производство-коммуналь объектлар зонасы” төзелеш корылмалары зонасына  кертергә (4нче кушымта );

4.Әлеге карарның 1.6.4. и 1.6.5.нче пунктлары 01.07.2019 елдан үз көченә керүен билгеләргә.

5. Әлеге карарны масса-күләм мәгълүмат чараларында бастырырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне  “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары М.И. Ксенофонтовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов

ТР ЧМР Чистай
шәһәре  Советының
28.02.2019елгы
32/1нче карарына
1нче кушымта

Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең жирдән  файдалану һәм төзелеш корылмалары  Кагыйдәсенең  территорияне шәһәр төзелеше зоналарына бүлү картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелүче үзгәрешләр:



ТР ЧМР Чистай
шәһәре Советының
28.02.2019елгы
32/1нче карарына
2нче кушымта

Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары Кагыйдәсенең территорияне шәһәр төзелеше зоналарына бүлү картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелүче үзгәрешләр:




ТР ЧМР Чистай
шәһәре Советының
28.02.2019елгы
32/1нче карарына
3нче кушымта

Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең жирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары Кагыйдәсенең территорияне шәһәр төзелеше зоналарына бүлү картасы

Гамәлдәге нигезләмә:



Кертелүче үзгәрешләр:




ТР ЧМР Чистай
шәһәре Советының
28.02.2019елгы
32/1нче карарына
4нче кушымта

Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары Кагыйдәсенең территорияне шәһәр төзелеше зоналарына бүлү картасы

Гамәлдәге нигезләмә:



Кертелүче үзгәрешләр:

